ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«02» ноябрь 2022 ел № 270

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы буенча 2022 елның IV кварталына торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен раслау турында

“Татарстан Республикасының Бәяләүчеләр союзы” коммерциясез партнерлыгының “бәяләр диапазонын билгеләү турында” 31.01.2022 елның 22 номерлы хаты нигезендә, "Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына бәяләү эшчәнлегенә бәйле рәвештә эксперт һәм консультацион ярдәм күрсәтү чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында” 19.11.2021 елның 1104 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, “Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәтләре белән тәэмин итү “Дәүләт программасын раслау турында” 03.10.2019 елның 888 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның IV кварталына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә «2020 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру кысаларында гражданнарның торак шартларын яхшырту чараларын үткәрүгә социаль түләүләрне исәпләү өчен торакның гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясен 38 500 сум күләмендә расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.agryz.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның гамәли көче 01.10.2022 елдан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ә. Фатыйховка йөкләргә.

**Җитәкче вазифаларын башкаручы** **Р. Р. Шәрипов**